# Татарстан Республикасы ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасының Конституция суды турында

### I БҮЛЕК. ТӨП ТӨШЕНЧӘЛӘР

I маддә. Конституция судының максатлары һәм бурычлары

Конституция суды хакимиятне бүлү принцибы нигезендә Татарстан Республикасының конституциячел төзелешен яклау, республиканың дәүләт суверенитетын, шәхеснең һәм гражданның Татарстан Республикасы Конституциясе тарафыннан танылган төп хокукларын һәм ирекен яклау максатларында гамәлгә куела.

Конституция суды Татарстан Республикасы Конституциясенең өстенлеген, аның республика территориясендә турыдан-туры тәэсирен, Татарстан Республикасының башка суверен дәүләтләр белән төзегән аңлашманамәләренең, Татарстан Республикасы законнарының, дәүләт органнарының башка норматив актларының республиканың Төп Законына туры килүен тәэмин итә.

2 маддә. Конституция суды эшчәнлегенең төп үзенчәлекләре

Конституция суды эшчәнлегенең төп үзенчәлекләре бәйсезлектән, законлылыктан, күмәклектән һәм хәбәрдарлыктан гыйбарәт.

3 маддә. Конституция судының бәйсезлеге

I. Конституция суды һәм аның судьялары үз эшчәнлекләрендә бәйсезләр, мөстәкыйльләр һәм бары тик Татарстан Республикасы Конституциясенә генә буйсыналар.

Конституция суды судьялары шәхес буларак кына эш итәләр.

2. Конституция суды һәм аның судьялары дәүләтнең яисә җәмәгатьчелекнең кайсы да булса органнарының, сәяси фиркаләрнең һәм хәрәкәтләрнең, дәүләт, иҗтимагый, кооператив, башка төрле предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның, урындагы затларның, милләтләрнең, халыкларның һәм иҗтимагый төркемнәрнең вәкилләре була алмыйлар.

3. Конституция суды карарлары, Татарстан Республикасы Конституциясенең төп мәгънәсенә яраклаштырып, судьяларның көнкүреш максатларыннан һәм сәяси омтылышларыннан азат булган хокукый карашларын белдерә.

4. Конституция суды эшләрне судьяларның ихтыярына читтән басым ясамаслык шартларда хәл итә һәм нәтиҗәләр чыгара. Алар дәүләтнең яисә җәмәгатьчелекнең кайсы да булса органнарыннан, урындагы затлардан һәм гражданнардан күрсәтмәләр соратып алырга тиеш түгел.

5. Конституция суды эшчәнлегенә ничек тә булса тыкшыну рөхсәт ителми һәм закон нигезендә җаваплылыкка китерә.

4 маддә. Конституция суды судьялары хокукларының тигезлеге

I. Судьялар Конституция суды утырышларында Конституция суды вәкаләтендәге барлык мәсьәләләрне хәл иткәндә тигез хокукларга ия булалар.

2. Конституция суды Рәисенең, аның урынбасарының һәм Конституция суды сәркатибенең вәкаләтләре әлеге Закон тарафыннан билгеләнә.

5 маддә. Конституция судының вәкаләтләре чоры һәм эш тәртибе

I. Конституция судының вәкаләтләре чоры чикләнмәгән.

2. Конституция суды – даими эшләүче орган.

6 маддә. Конституция суды карарларының һәм таләпләренең мәҗбүрилеге һәм катгыйлыгы

1. Конституция судының үз вәкаләтләре чикләрендә кабул ителгән карарларының Татарстан Республикасының бөтен территориясендә барлык дәүләт органнары тарафыннан, шул исәптән судлар, шулай ук милек рәвешенә карамастан, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан, урындагы затлар һәм гражданнар тарафыннан үтәлүе мәҗбүри.

2. Конституция суды нәтиҗәләре Татарстан Республикасы Югары Советына яисә аның Президиумына, Татарстан Республикасы Президентына җиткерелергә тиеш һәм, алар тарафыннан каралып, Конституция суды нәтиҗәләрен искә алып, карар кабул ителергә тиеш.

3. Конституция судының аңлатмалар, киңәшләр бирү турында, белгечләр биреп тору турында, каралучы мәсьәләләр буенча белгечләр фикерен бәян итү турында карарлары, тәкъдимнәре, башка төрле нәтиҗәләре һәм таләпләре алар җибәрелгән барлык органнар, урындагы затлар һәм гражданнар өчен мәҗбүри.

4. Конституция судының карарлары, бәяләмәләре, башка төрле нәтиҗәләре, тәкъдимнәре һәм таләпләре алынган көненнән бер ай эчендә яисә Конституция суды билгеләгән вакытта каралырга тиеш һәм карау нәтиҗәләре хакындагы җавап Конституция судына җибәрелергә тиеш.

5. Конституция судының карарларын, тәкъдимнәрен һәм башка нәтиҗәләрен караудан яисә үтәүдән баш тарту яки тайпылу, аларны карау вакытын чигерү, шулай ук судьяларны белә торып ялгыш юлга кертү закон нигезендә җаваплылыкка китерә.

Конституция судының үз вәкаләтендәге мәсьәләләр турында карарлары катгый һәм аларга шикаять белдерелми.

7 маддә. Конституция судының закон чыгару инициативасы

Конституция суды Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы Югары Советында закон чыгару

инициативасы хокукына ия.

8 маддә. Конституция суды турында законнар

Конституция судының максатлары, вәкаләте, эшчәнлеген оештыру һәм эшчәнлеге тәртибе Татарстан Республикасы Конституциясе һәм әлеге Закон белән билгеләнә.

9 маддә. Конституция судының Регламенты

Конституция судының эшчәнлеген регламентлаштыру, гамәли /процессуаль/ документларны төзү мәсьәләләре,шулай ук Конституция суды эшчәнлегенең эчке мәсьәләләре, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм әлеге Закон тарафыннан җайга салынмаганлыктан һәм өстәмә җайга салу кирәк булганлыктан, Конституция суды кабул итә торган Конституция суды Регламенты белән билгеләнә.

## П БҮЛЕК

### Татарстан Республикасы Конституция суды составы, сайлау тәртибе һәм судьяларының статусы

10 маддә. Конституция судын сайлау

I. Конституция суды Конституция суды Рәисеннән, Рәис урынбасарыннан һәм Конституция судының алты әгъзасыннан гыйбарәт. Конституция судының судьялары Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан раслана.

Конституция суды судьяларына кандидатларны Татарстан Республикасы Югары Советына Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе бер үк санда тәкъдим итәләр.

Конституция суды Рәисе һәм Рәис урынбасары Конституция

суды судьялары тәкъдиме белән Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан раслана.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы булып 30 яшьтән яшьрәк булмаган һәм 60 яшьтән дә олы булмаган, сайлау хокукына ия булган, Конституция суды судьясы вазыйфаларын үтәү өчен кирәкле югары юридик белгечлеге булган, әдәпле, югары юридик белемле, шулай ук юридик белгечлек буенча фәнни дәрәҗәсе яисә ун елдан да ким эш стажы булмаган Татарстан Республикасының гражданы сайлана ала.

3.Конституция судының һәр судьясы аерым-аерым шәхси сайлана. Татарстан Республикасы Югары Советының мәгълүм санлы составының күпчелек тавышын җыйган зат сайланган дип санала.

4. Конституция суды составының өчтән икесе сайланса, ул үз эшчәнлегенә керешә ала.

5. Конституция суды составыннан судья, шул исәптән Конституция суды Рәисе яисә аның урынбасары киткән очракта, Югары Совет чираттагы сессиясендә аның урынына башка кешене сайлый.

Конституция суды әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә үз составыннан Конституция суды сәркатибен сайлый.

II маддә. Конституция суды судьясының анты

I. Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе Югары Совет утырышында Конституция суды судьялары булып сайланучыларны ант иттерә.

2. Татарстан Республикасының Конституция суды судьясы итеп сайланучы зат Татарстан Республикасы дәүләт телләренең берәрсендә түбәндәге эчтәлектәге ант итә: "Бары тик Татарстан Рес-

публикасы Конституциясенә генә буйсынып, Татарстан Республикасының Конституция суды судьясы вазыйфаларын намуслы һәм гадел үтәргә, Татарстан Республикасының конституциячел төзелешен һәм Төп Законының өстенлеген сакларга тантаналы төстә ант итәм".

12 маддә. Конституция суды судьясына хас булмаган гамәлләр

I. Конституция суды судьясы бер үк вакытта халык депутаты булалмый, дәүләт, хуҗалык, җәмәгать органнарында һәм оешмаларында түләүле эшләрдә эшли алмый, эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнә алмый. Конституция суды судьясы фәнни, укыту, әдәби һәм башка төрле иҗади эшчәнлек белән шөгыльләнә ала.

2. Конституция суды судьясының, хөкем органнарында яисә хокук кулланучы органнарда законлы вәкиллек итүдән гыйре, яклауга яисә вәкиллек итүгә хакы юк, кемнәргәдер хокуклар бирүдә һәм аларны вазыйфаларыннан азат итүдә яклый алмый.

3. Конституция суды судьясы сәяси фиркаләр һәм хәрәкәтләр эшчәнлегендә катнаша алмый.

4. Конституция суды судьясы законда билгеләнгән тәртип - тә һичшиксез үзенең гражданлык һәм сайлаучы ихтыярын белдерергә хаклы.

13 маддә. Конституция суды судьяларының вәкаләтләре чоры

I. Конституция суды судьясының вәкаләтләре чоры чикләнмәгән.

2. Конституция суды судьясы үз вазыйфаларын 70 яшькә кадәр үти ала.

14 маддә. Конституция суды судьясының алыштыргысызлыгы

Конституция суды судьясы алмаштырылмый. Ул үзенең ризалыгыннан башка бүтән эшкә күчерелә алмый, һәм аның вәкаләтләре әлеге Законда билгеләнгән тәртип һәм сәбәпләр аркасында гына туктатылырга яисә туктатып торылырга мөмкин.

15 маддә. Конституция суды судьясының кагылгысызлыгын гарантияләү

1. Конституция суды судьясы, Конституция суды рөхсәтеннән башка, җинаять җаваплылыгына тартыла алмый, кулга алына алмый, мәҗбүри рәвештә тотып китерелә алмый, яисә, административ хокук бозган урыннарда салына торган штрафлардан гайре, административ җәзага тартыла алмый.

2. Конституция суды судьясына карата җинаять эше кузгату, шулай ук административ хокук бозулар турында җинаять эшен карарга кертү Татарстан Республикасы Прокуроры тарафыннан гына башкарылырга мөмкин. Конституция суды судьясының торагына яки аның хезмәт урынына, шәхси транспортына яисә ул хезмәтендә файдалана торган транспортка үтеп керү, анда тикшерү, тентү яисә әйберләрендә казыну, Конституция суды судьясын шәхси тикшерү яки шәхси тентү, шулай ук аның әйберләрен һәм документларын тикшерү яисә тартып алу Татарстан Республикасы Прокуроры санкциясеннән башка рөхсәт ителми һәм әлеге судьяга карата эш кузгатылганда гына рөхсәт ителә.

3. Конституция судының җинаять кылуда шикле судьясы административ хокук бозулар турында эшләр башкару тәртибендә эчке эшләр органнарына тотып китерелсә, аның шәхесе ачыклануга, кичекмәстән азат ителергә тиеш.

4. Конституция суды судьясын гаепләү турында җинаять эше, үзенең таләбе нигезендә, судка кадәр Татарстан Республикасы Югары суды тарафыннан беренчел баскычта /инстанциядә/ каралырга тиеш.

5. Судта тиешле эшне карауны кузгату өчен,Конституция суды рөхсәтеннән башка,Конституция суды судьясы ирексезләп табиблык сыйфатындагы гамәлләргә җәлеп ителә алмый, ул хезмәткә сәләтсез яисә сәләте чикләнгән дип танылa алмый.

6. Конституция суды судьясы Конституция суды утырышларында белдергән фикере өчен, шулай ук Конституция судында кабул ителүче карарлар белән бәйле тавыш бирүләрнең нәтиҗәләре нигезендә җаваплылыкка тартыла алмый.

16 маддә. Конституция суды судьясының вәкаләтләрен туктатып тору

I. Конституция суды судьясының вәкаләтләре Конституция суды карары нигезендә түбәндәге очракларда туктатып торыла, әгәр:

I/ Конституция суды судьясы урынына сайлаганда Татарстан Республикасы Конституциясендә һәм әлеге Законда билгеләнгән тәртип бозылса;

2/ судьяны кулга алырга яисә аны җинаять җаваплылыгына тартырга Конституция судының рөхсәте булса;

3/ судьяга хас булмаган гамәлләр кылса;

4/ судья Конституция суды тарафыннан өйрәнелә торган яисә карарга кабул ителгән мәсьәлә турында, әлеге мәсьәлә хакында карар кабул ителгәнче үк, массакүләм мәгълүмат чараларында үз фикерен бәян итсә;

5/ судья табибләр комиссиясе тарафыннан озак вакытка үз вазыйфаларын башкарырга сәләтсез дип табылса;

6/ судьяга ирексезләп табиблык гамәлләре кылынган булса яисә закон көченә кергән суд карары нигезендә аның хезмәткә сәләте чикләнгәнлеге беленсә;

7/ судья закон көченә кергән карар нигезендә билгесез сәбәпләр аркасында хезмәт вазыйфаларын үтәмәгән дип табылса;

8/ судья Конституция суды утырышларында өч мәртәбә рәттән сәбәпсез катнашмаса.

2. Конституция суды судьясының вәкаләтләрен туктатып торырлык сәбәпләр Конституция суды карары нигезендә раслана, әлеге карар шушы вакыйгалар беленгән көннән бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

3. Конституция суды, судьяның вәкаләтләрен туктатып торырлык сәбәпләр беткәнче, аның вәкаләтләрен туктатып тора.

4. Конституция суды судьясының вәкаләтләрен туктатып тору аңа эш хакы түләмәслек яисә эш хакының күләмен киметеп торырлык сәбәп була алмый һәм судьяны әлеге Законда күрсәтелгән кагылгысызлык гарантияләреннән мәхрүм итми.

17 маддә. Конституция суды судьясының вәкаләтләрен туктату

1. Конституция суды судьясының вәкаләтләре түбәндәге сәбәпләр аркасында туктатыла:

1/ отставкага китү турында үтенече булса;

2/ Конституция суды судьясы вазыйфаларын үтәмәслек яшькә җитсә;

3/ аны гаепләү турында закон көченә кергән хөкем карары булса;

4/ закон көченә кергән хөкем карары нигезендә хезмәткә сәләтсез дип табылса;

5/ закон көченә кергән хөкем карары нигезендә үлгән дип саналса;

6/ Татарстан Республикасы гражданлыгы туктатылса;

7/ үлсә.

2. Конституция суды судьясының вәкаләтләре Конституция суды карары нигезендә туктатыла.

3. Конституция суды судьясының вәкаләтләрен туктату белән бергә, аның Конституция суды Рәисе, Рәис урынбасары сыйфатындагы, шулай ук Конституция суды сәркатибе сыйфатындагы вәкаләтләре дә туктатыла.

18 маддә. Конституция суды судьясы

1. Конституция суды судьясы Конституция суды карамагындагы барлык мәсьәләләр буенча хәлиткеч тавыш бирү хокукыннан файдалана, аның барлык утырышларында катнашырга хаклы, аның карамагындагы теләсә нинди мәсьәләне өйрәнүне һәм аны Конституция суды утырышына кертүне таләп итә ала, шулай ук әлеге Законда каралган башка хокуклардан файдалана.

2. Татарстан Республикасы халык депутатлары эшчәнлегенең төп гарантияләре Конституция суды судьяларына да кагыла.

3. Конституция суды судьясының үзенчәлекле фикерләрен, тәкъдимнәрен һәм таләпләрен бергәләшеп бәян итәргә хакы юк.

4. Конституция суды өйрәнә торган һәм карарга кабул иткән мәсьәлә турында карар кабул ителгәнче, Конституция суды судьялары әлеге мәсьәлә хакындагы фикерен Конституция суды утырышларында гына ачыктан-ачык белдерә ала.

19 маддә. Конституция суды Рәисе

1. Конституция суды Рәисе:

I/ Конституция суды утырышларын әзерләүгә җитәкчелек итә;

2/ Әлеге Законда билгеләнгән очракларда шушы Закон таләпләренә туры килми торган үтенеч һәм гозерләрне тутыруда җибәрелгән җитешсезлекләрне төзәтү кирәклеген күрсәтеп, аларны кире кайтара.

3/ Конституция судына утырышларында каралырга тиешле мәсьәләләр тәкъдим итә;

4/ Конституция судын җыя һәм аның утырышларында рәислек итә;

5/ кичектергесез очракларда, бигрәк тә төзәтеп булмаслык зыян киләсен ачыклаганда, мондый эшләрне Конституция суды караганчы, дәүләтнең тиешле органнарына һәм урындагы затларга халыкара аңлашманамәләрне ратификацияләү барышын, норматив актларның тәэсирен туктатып тору турында таләпләр җибәрә;

6/ Рәис урынбасарының һәм Конституция суды сәркатибенең вазыйфаларын билгели, Конституция суды судьяларына йөкләмәләр бирә һәм Конституция суды судьяларына вазыйфалар бүлеп бирү хакында тәкъдимнәрен Конституция суды раславына кертә;

7/ Конституция суды сәркатиплегенә гомуми җитәкчелек итә, Конституция суды хезмәткәрләрен, хезмәт күрсәтүче кече персоналны эшкә алу һәм эштән азат итү хокукыннан файдалана; Конституция суды сәркатиплеге, аның төзелеше һәм штат расписаниесе хакындагы положениене Конституция суды раславына кертә; Конституция суды сәркатиплегенең бүлекләре, хезмәт күрсәтүче бүлекләре һәм башка бүлекчәләре турында положениене раслый;

8/ Конституция суды турында законнар һәм Конституция судының Регламенты нигезендә башка вәкаләтләр башкара.

2. Конституция суды Рәисе әмерләр /приказлар/ һәм боерыклар бастырып чыгара. Конституция суды судьясы үтәргә тиешле

карарларны яисә аның вазыйфаларын билгеләүче карарларны Конституция суды Рәисе боерыклар рәвешендә бастырып чыгарырга тиеш.

3. Әлеге маддәнең беренче өлешендәге 2 һәм 6 пунктларда күрсәтелгән очракларда Конституция суды Рәисе үз карарларын һәм таләпләрен дәлилләнгән тәшенчә рәвешендә бәян итә; мондый тәшенчә, Конституция суды Рәисе яисә Конституция суды тарафыннан карала башлаганчы ук, тиешенчә гамәлдән чыгарылырга яки кире чакыртып алынырга мөмкин.

4. Әлеге Законның I7 маддәсендә каралган очраклардан гайре, судья Конституция суды Рәисе вазыйфаларыннан вәкаләтләрен туктату хакындагы шәхси гаризасы нигезендә генә азат ителә ала. Конституция суды Рәисенең вәкаләтләреннән баш тартуы Конституция суды карары тарафыннан раслана.

5. Конституция суды Рәисенең намусы һәм абруе Закон тарафыннан саклана.

20 маддә. Конституция суды Рәисенең вазыйфаларын вакытлыча үтәү

I. Конституция суды Рәисе булмый торганда яисә вәкаләтләреннән баш тартканда, аның вазыйфаларын вакытлыча Конституция суды Рәисе урынбасары башкарып тора.

2. Конституция суды Рәисе урынбасары булмый торганда, вәкаләтләрен туктатып торганда, туктатканда, вәкаләтләреннән баш тартканда, әгәр ул әлеге маддәнең беренче өлешендә каралганча Конституция суды Рәисе вазыйфаларын башкарырга тиеш булса, әлеге вазыйфаларны Конституция суды сәркатибе вакытлыча башкарып тора.

3. Конституция суды сәркатибеннән соң Конституция суды Рәисе вазыйфаларын үтәү чираты Конституция суды карары нигезендә билгеләнгән судьяга күчә.

21 маддә. Конституция суды Рәисенең урынбасары

I. Конституция суды Рәисе урынбасары, Конституция суды Рәисе кушуы буенча, шулай ук Конституция суды Рәисе булмый торганда, вәкаләтләрен туктатып торганда, туктатканда яисә вәкаләтләреннән баш тартканда, аның вазыйфаларын башкара.

2. Әлеге Законның I7 маддәсендә каралган очраклардан тыш, судья Конституция суды Рәисе урынбасары вазыйфаларыннан вәкаләтләрен туктату хакындагы шәхси гаризасы нигезендә генә азат ителә ала. Конституция суды Рәисе урынбасарының вәкаләтләреннән баш тартуы Конституция суды карары тарафыннан раслана.

22 маддә. Конституция суды сәркатибе

I. Конституция суды сәркатибе Конституция суды утырышында биш елга сайлана.

2. Конституция суды сәркатибе, Конституция суды судьясы вазыйфаларын үтәү белән бергә, Конституция суды Регламентында күрсәтелгән Конституция суды эшләрен оештыру вазыйфаларын башкара.

3. Судьяның Конституция суды сәркатибе буларак вәкаләтләре вакыты узгач яисә вакытыннан алда туктатыла һәм Конституция суды карары белән раслана.

4. Судьяны Конституция суды сәркатибе урынына Конституция судының беренче составын сайлаган көннән яисә тиешле урын бушаган көннән ике ай эчендә сайлыйлар.

23 маддә. Конституция суды судьясының хезмәт хакы, эштән киткәндә түләнә торган пособиесе һәм судьяның җәмгыяви, көнкүреш тәэминаты

I. Конституция суды Рәисенең, Рәис урынбасарының, сәркатибенең һәм Конституция суды әгъзаларының хезмәт хакы күләмен Татарстан Республикасы Югары Советы билгели һәм яңадан карый.

Бу очракта Конституция суды Рәисенең хезмәт хакы Татарстан Республикасының закон чыгару һәм башкарма хакимиятенең югары урындагы затларының хезмәт хакыннан ким булмаска тиеш.

Конституция суды судьясының хезмәт хакына өстәмәләр билгеләнә алмый.

2. Конституция суды әгъзасының хезмәт хакы ул бу урында эшләгәндә киметелергә тиеш түгел.

3. Конституция суды судьясы, яше җитеп, эштән киткәндә яисә сәламәтлеге какшау аркасында озак вакытлар үз вазыйфаларын башкармаганда, аңа еллык хезмәт хакы күләмендә пособие түләнә. Үз теләге буенча Конституция судыннан отставкага киткән судьяга еллык хезмәт хакы күләменнән артмаган эштән китү пособиесе бирү турында Конституция суды карар чыгара ала.

4. Конституция суды судьяларын пенсия белән тәэмин итү тәртибен Татарстан Республикасы законнары билгели.

5. Һәр судьяга сайланганнан соң 6 ай эчендә, үзе белән яшәүче гаилә әгъзалары белән бергә, аерым квартира яисә йорт бирелергә тиеш.

24 маддә. Конституция суды судьяларының дәүләт органнары утырышларында катнашу хокукы

I. Конституция суды Рәисе, аның урынбасары, Конституция суды әгъзалары Татарстан Республикасының теләсә кайсы дәүләт органы утырышларында, шул исәптән ябык утырышларында да катнашырга хаклы.

## Ш БҮЛЕК

### Татарстан Республикасының Конституция суды вәкаләтләре һәм эшчәнлегенең тәртибе

### I КИСӘК. Конституция судының вәкаләтләре һәм эшчәнлегенең төп кагыйдәләре

25 маддә. Конституция судының вәкаләтләре

I. Конституция суды Конституциягә туры килү-килмәү турында

түбәндәге эшләрне карый:

I/ Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Югары Советының һәм аның Президиумының норматив карарларын;

2/ Татарстан Республикасы Президентының һәм Министрлар кабинетының норматив актларын;

3/ Татарстан Республикасының халыкара аңлашманамәләрен.

Конституция суды Татарстан Республикасының югары дәүләт органнары арасындагы, шулай ук республика буйсынуындагы районнар һәм шәһәрләр хакимияте органнары арасындагы вәкаләтләр хакындагы бәхәсләрне карый.

2. Татарстан Республикасының Конституция суды Татарстан Республикасы Югары Советы, аның Президиумы, даими комиссияләре һәм Парламент контроль комитеты гозере буенча, шулай ук инициативасы нигезендә Татарстан Республикасы Президенты гамәлләренең һәм карарларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирә.

3. Конституция судының тикшерү вазыйфалары тикшерү /следствие/, прокуратура органнарының карарларына һәм судларның җинаять, гражданлык, административ, арбитраж эшләр буенча хөкем карарларына һәм гомуми карарларына кагылмый.

4. Татарстан Республикасының Конституция суды, Татарстан Республикасы Конституциясенә таянып, хокукларны аңлап, башка органнар вәкаләтләренә караган хакыйкый вакыйгаларны билгеләүдән һәм тикшерүдән тыелып, эшләрне хәл итә һәм бәяләмәләр бирә.

26 маддә. Күмәклек

Эшләрне карау һәм бәяләмәләр бирү, Конституция судының Регламентын кабул итү һәм аңа үзгәрешләр кертү, Конституция суды судьясының вәкаләтләрен туктатып тору һәм туктату турында, аның кагылгысызлыгын чикләү турында мәсьәләләрне карау Конституция судында исемлектәге судьяларның өчтән икесеннән дә ким

булмаган составта уздырыла. Башка мәсьәләләрне караганда исемлек составындагы судьяларның яртысыннан артыгы катнашса, бу Конституция суды утырышы тулы хокуклы була.

Кворумны исәпләү өчен Конституция суды судьяларының исемлек составын билгеләгәндә, әлеге Закон тарафыннан күрсәтелгән тәртиптә вәкаләтләре туктатып торылган судьялар исәпкә алынмый.

Әгәр судьяның әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә вәкаләтләре туктатып торылмаган булса, ул Конституция суды утырышында катнашудан мәхрүм ителә алмый.

Әгәр судьяның мәсьәләнең ахыры белән турыдан-туры яисә читләтеп кызыксынуы аркасында риясызлыгына шик туарлык булса, ул бу мәсьәләне караудан үзе баш тартырга тиеш. Судьяны мәсьәләне карауда катнашудан читләштерү яисә читләштермәү турындагы карарны Конституция суды кабул итә.

27 маддә. Хәбәрдарлык

I. Конституция суды үзенең утырышлары турында массакүләм мәгълүмат чараларында хәбәр итә.

2. Конституция суды утырышлары ачык уздырыла. Конституция суды рәисе рөхсәте белән утырышларда массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре, башка затлар катнаша ала. Катнашучылар утырыш барышы хакында язмалар, стенограмма алып барырга һәм утырган урыннарыннан тасмага яздырып алырга хаклы.

3. Конституция суды утырышларын кинога, фотога, видеоязмага төшерү, радио һәм телевидение аша трансляцияләү аның рөхсәте белән генә башкарыла.

4. Конституция суды дәүләт серен яисә закон тарафыннан саклана торган башка серне сакларга һәм гражданнарның иминлеген тәэмин итәргә кирәк булган очракларда, Конституция суды ябык

утырыш билгели ала.

5. Конституция суды Регламент бозучыларны, Конституция суды утырышын тиешенчә алып баруга комачаулаучыларны, кисәтү ясаганнан соң, утырыштан чыгарып җибәрә ала.

6. Конституция суды судьялары киңәшмәсенә бары тик беркетмә алып баруны һәм киңәшмәне тиешенчә уздыруны тәэмин итүче Конституция суды хезмәткәрләре генә кертелергә мөмкин. Башка затларның катнашуы рөхсәт ителми. Киңәшмәдә, шул исәптән тавыш бирүдә катнашучы Конституция суды судьяларының һәм хезмәткәрләренең киңәшмә барышында әйтелгән фикерләрен игълан итәргә хаклары юк.

7. Конституция суды карарлары һәр очракта да ачыктан-ачык хәбәр ителә һәм һичбер төрле чикләүләрсез халыкка игълан ителә.

28 маддә. Тикшерүләрне телдән алып бару

I. Конституция суды утырышта катнашучыларның аңлатмаларын тыңларга һәм булган документларны игълан итәргә тиеш.

2. Әгәр барлык судьяларда һәм утырышта катнашучыларда булган документлар утырыш барышында телдән бәян ителгән булса, Конституция суды аларны игълан итмәсә дә була.

29 маддә. Эшне алып бару теле

I. Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Конституция судындагы эшләр Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә алып барыла.

2. Утырышта катнашучыларның татар һәм урыс телләрен белмәгәннәре туган телләрендә чыгыш ясыйлар һәм тәрҗемәче хезмәтеннән файдаланалар.

30 маддә. Конституция судының мәсьәләләрне карау вакыты

I. Конституция суды аңлашманамәнең, норматив актның, урындагы затның гамәленең һәм карарының Конституциягә туры килүен тикшерү турында әлеге Закон таләпләренә җавап бирерлек үтенеч яисә гарызнамә алганнан соң яки Конституция суды эшчәнлегенә кагылучы мәсьәләне карарлык сәбәп туганнан соң, ике атнадан да соңга калмыйча, мәсьәләне өйрәнергә керешергә тиеш.

2. Әгәр әлеге Законда башкасы күрсәтелмәгән булса, Конституция судында мәсьәлә тиешле материаллар алу яисә тиешле сәбәпләрне ачыклау мизгеленнән башлап алты ай эчендә каралырга һәм аның буенча карар кабул ителергә тиеш.

31 маддә. Конституция суды хәл итә торган эшләрнең һәм ул чыгара торган бәяләмәләрнең чикләре

I. Конституция суды бары тик хокук мәсьәләләрен генә билгели һәм карый.

2. Конституция суды үтенечтә яисә гарызнамәдә Конституциягә туры килүенә шик белдерелгән предмет буенча гына һәм аңлашманамәнең яисә норматив актның шик белдерелгән өлеше, шулай ук урындагы затның гамәле һәм карары буенча гына карар чыгара һәм бәяләмә бирә. Конституция суды бу очракта үтенечтә яисә гарызнамәдә бәян ителгән сәбәпләргә һәм ниятләргә бәйле булырга тиеш түгел.

3. Үтенечтә яисә гарызнамәдә әйтелмәгән булса да, Конституция суды, норматив актның Конституциягә туры килү-килмәвен тикшереп, бер үк вакытта тикшерелгән норматив актка яисә аның эчтәлеген тәшкил итүче положениеләргә нигезләнгән норматив актларга карата да үз карарын чыгара ала.

4. Конституция суды үз теләге белән бәяләмә бирергә хаклы булган очракларда, мәсьәләне карау чикләрен Конституция суды үзе билгели.

5. Конституция суды норматив актның Конституциягә туры килү-килмәвен тикшергән вакытта норматив актның эчтәлеген һәм максатларын төп мәгънәсендә, шулай ук норматив актка рәсми һәм башкача бирелгән аңлатманың эчтәлеген һәм максатларын да, әлеге норматив актны куллану тәҗрибәсен дә күз алдында тота.

6. Конституция судының аңлашманамәләрнең һәм норматив актларның проектларын алдан тикшерергә һәм рецензияләргә, үзенә караган мәсьәләләр буенча кемгә дә булса консультация бирергә, имза салынмаган аңлашманамәләрнең, кабул ителмәгән норматив актларның Конституциягә туры килү-килмәве турында фикерләр әйтергә хакы юк.

32 маддә. Конституция суды утырышы

1. Конституция суды түбәндәге утырышлар уздыра:

- Конституция судының агымдагы эшчәнлеге турында утырышлар;

- әзерлек утырышы;

- аңлашманамәләрнең, норматив актларның Конституциягә туры килү-килмәве турындагы, Татарстан Республикасының югары дәүләт органнары арасында, республика буйсынуындагы районнарның һәм шәһәрләрнең хакимият органнары арасында вәкаләтләр хакындагы эшләрне тыңлау буенча утырыш;

- бәяләмәләр бирү турында утырыш.

2. Агымдагы эшләр буенча утырышларны, әзерлек утырышларын уздыру тәртибен һәм барышын, әлеге Закон һәм Конституция судының Регламентын үтәгән килеш, Конституция суды билгели.

3. Конституция судының бер үк утырышында бер яисә берничә мәсьәлә каралырга тиеш. Халыкара аңлашманамәнең, норматив актның Конституциягә туры килү-килмәве турында һәр эшне карау, шулай ук бәяләмә бирүнең һәр очрагын карау аерым утырышта уздырыла һәм,әлеге Законда каралган очраклардан тыш, башка мәсьәләләр белән бергә карала алмый.

4. Конституция суды утырышы өзлексез алып барыла, моңа ял итү өчен һәм утырышта катнашучыларга йомгаклау нотыгын әзерләү өчен бирелгән вакыт керми; утырышны алып баруга комачаулаучы шартлар килеп чыкканда, шулай ук башка мәгълүм сәбәпләр аркасында утырыш өзелергә мөмкин.

5. Конституция суды тәнәфес вакытында башка мәсьәләләр карый алмый. Тәнәфестән соң мәсьәләне карау туктатылган мизгеленнән дәвам иттерелә.

6. Әгәр Конституция суды каралачак мәсьәләне җитәрлек әзерләнмәгән яисә өстәмә аңлатуга мохтаҗ дип санаса һәм бу аңлатуга әлеге утырышта ирешеп булмас дип санаса, яки катнашулары мәҗбүри булган шаһит яисә эксперт утырышка килмәсә, я тиешле материаллар тәкъдим ителгән булмаса, Конституция суды утырышы яки анда аерым мәсьәләне карау кичектерелергә мөмкин. Бу очракларда Конституция суды утырышның яисә мәсьәләне карауның кайчанга кадәр кичектерелүен хәбәр итә.

7. Конституция судының яисә мәсьәләнең каралуын кичектерү, кичектерелгән утырыш дәвам иттерелгәнче, башка мәсьәләләрне карарга комачауламый. Кичектерелгән утырыш башланган өлешеннән яисә туктатылган мизгеленнән дәвам иттерелә.

8. Татарстан Республикасының Конституция суды утырышының тәртибе Конституция суды Регламенты тарафыннан билгеләнә.

9. Конституция суды утырышында тәртип бозу, рәислек итүченең яисә утырышның тәртибен саклау өчен махсус вәкаләт бирелгән затның боерыгына буйсынмау, Конституция суды кабул иткән кагыйдәләрне санга сукмау законда күрсәтелгән җаваплылыкка китерә.

33 маддә. Конституция суды утырышында рәислек итүче

I. Конституция суды утырышында Конституция суды Рәисе рәислек итә, яисә, ул булмаган очракта, аның кушуы буенча - Конституция суды Рәисе урынбасары, ә икесе дә булмаганда Конституция суды тарафыннан әлеге очрак өчен сайланган судья рәислек итә. Утырышта нотык ясаучы судья рәислек итә алмый.

2. Рәислек итүче Конституция суды утырышына җитәкчелек итә, мәсьәләне тикшерүнең тәртибен, тулылыгын һәм күпкырлылыгын тәэмин итүче чаралар кабул итә, тикшерелә торган мәсьәләгә карамаган яисә Конституция суды карамагында булмаган мәсьәләләргә кагылучыларны туктата; чыгышларның әзлеклелеген үзбаштан өзгәндә, рәислек итүченең таләпләрен үтәмәгәндә, мәсхәрәләүче һәм тупас гыйбарәләр кулланганда, Конституциягә каршы дәлилләрне һәм өндәмәләрне игълан иткәндә, аларны чыгыш ясаудан мәхрүм итә.

3. Рәислек итүче утырышта тәртип бозучы яисә рәислек итүченең законлы боерыкларына буйсынмаучы һәр кешене утырыш залыннан чыгарып җибәрә. Әгәр дә утырыштагы катнашучыга рәислек итүченең кисәтүе тәэсир итмәсә, утырышта катнашучы судьяларның күпчелеге ризалык бирсә, әлеге зат утырыштан чыгарып җибәрелә.

4. Рәислек итүче Конституция суды киңәшмәсенә җитәкче-

лек итә, судьяларга үз фикерләрен ирекле һәм каршылыксыз белдерерлек шартлар тәэмин итә, тавыш бирүне, карарны теркәүне һәм бәян итүне оештыра.

34 маддә. Конституция суды утырышында катнашучылар

I. Конституция суды утырышында Татарстан Республикасының Югары суды Рәисе, Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды Рәисе, Татарстан Республикасы Прокуроры һәм Татарстан Республикасының юстиция министры катнаша, алар барлык каралучы мәсьәләр турында да үз фикерләрен бәян итә алалар.

2. Конституция суды утырышына яклар һәм аларның вәкилләре чакырыла;

Конституциягә туры килү-килмәвен тикшерергә тиешле аңлашманамә имза салучы яисә норматив акт бастырып чыгаручы дәүләт органнары вәкилләре;

халыкара аңлашманамәнең яисә норматив актның Конституциягә туры килү-килмәвен тикшерү турында үтенеч яисә бәяләмә бирүне сорап гарызнамә жибәрүче дәүләт органнарының, халык депутатлары төркемнәренең, урындагы затларның вәкилләре, шулай ук югарыда күрсәтелгән урындагы затларның вәкилләре;

гамәлләренең һәм карарларының Конституциягә туры килү-килмәве тикшерелүче урындагы затлар һәм аларның вәкилләре.

3. Яклар Конституция суды чакыруы буенча судка килергә, аңа аңлатма һәм сорауларга җаваплар бирергә тиешләр. Яклар үзләренең каралучы эше буенча үз фикерләрен белдерергә һәм каршы якка, шаһитларга һәм экспертларга

сорау бирергә, башка якларның фикерләре белән танышырга хаклы.

4. Конституция суды утырышы турында мәгълүмат, утырышның көн тәртибе, карарларның, бәяләмәләрнең һәм башка чыгарылмаларның проектлары, ә кирәк чакта башка документлар да, утырышта катнашучыларга утырыш башланганчы ун көннән дә соңга калмыйча җибәрелә. Якларга үз эшенә кагылучы материаллар гына җибәрелә.

5. Конституция суды утырышына Татарстан Республикасының Югары суды Рәисе, Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды Рәисе, Татарстан Республикасының Прокуроры, Татарстан Республикасының юстиция министры, шулай ук якларның һәм аларның вәкилләре килмәү эшне карауга, карарлар кабул итүгә, бәяләмәләр бирүгә һәм нәтиҗәләр чыгарырга комачауламый.

6. Эшне карау яисә бәяләмәләр бирү белән бәйле булмаган Конституция суды утырышларында Конституция суды Рәисе чакыруы буенча консультантлар, экспертлар һәм башка затлар катнашырга мөмкин.

7. Татарстан Республикасының Конституция суды утырышларында Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Премьер-министры катнаша ала.

35 маддә. Дәүләт пошлинасы

I. Норматив актның Конституциягә туры килү-килмәвен тикшерү турындагы һәр үтенечкә минималь хезмәт хакы күләмендә дәүләт пошлинасы салына. Конституция суды тарафыннан бәяләмә бирү хакындагы һәр гарызнамәгә минималь хезмәт хакының яртысы күләмендә дәүләт пошлинасы салына.

2. Конституция суды карарларының, бәяләмәләренең яисә башка

чыгарылмаларының күчермәләрен кабат биргән өчен, карарларның, бәяләмәләрнең һәм башка чыгарылмаларның күчермәләрен башка затларга биргән өчен минималь хезмәт хакының егермедән бере күләмендә дәүләт пошлинасы алына.

3. Әгәр артык түләнмәгән булса, Конституция суды дәүләт пошлинасын кире кайтарып бирә алмый. Мондый очракларда артык түләнгән сумманы кайтару турында Конституция суды Рәисе, әлеге мәсьәләне өйрәнүче судья, нотыкчы судья яисә Конституция суды боерык бирә.

4. Үтенечне яисә гарызнамәне кире алу дәүләт пошлинасын киметүгә дә, кире кайтарып бирүгә дә сәбәп була алмый.

36 маддә. Якларның чыгымнарын каплау чыганаклары

I. Яклар Конституция суды эшендә катнашу һәм Конституция суды эшләгән урында булу белән бәйле чыгымнарны үз исәпләренә каплыйлар.

2. Дәүләт пошлинасы түләгән, Конституция судында эш алып бару һәм суд эшләгән урында булу белән бәйле башка чыгымнарны түләгән як гражданлык суд эшләрен алып бару яисә арбитраж гамәл тәртибендә бу чыгымнарны кире кайтаруны таләп итә алалар.

37 маддә. Конституция суды утырышына чакырулар

Конституция судының эш каралучы яисә бәяләмәләр бирү турында мәсьәлә карала торган утырышына кирәкле мәгълүматлары яисә материаллары булган затлар шаһит буларак һәм карала торган мәсьәлә буенча махсус белемнәре булган затлар эксперт сыйфатында чакырылырга мөмкин.

2. Шаһитлар һәм экспертлар чакыру буенча судка килергә, дөрес мәгълүматлар, кирәкле материаллар һәм сорауларга жа-

вап бирергә тиешләр.

3. Конституция суды утырышында шаһитлар һәм экспертлар, каралучы эш турында белгәннәрен Конституция судына бәян итәчәкләрен белдереп, ант итәләр. Шаһитның һәм экспертның ант тексты Конституция суды Регламенты тарафыннан билгеләнә.

4. Шаһитларның һәм экспертларның Конституция суды утырышында катнашу белән бәйле чыгымнары Татарстан Республикасының республика бюджеты исәбеннән кире кайтарыла.

38 маддә. Беркетмә алып бару

I. Конституция суды утырышларында беркетмә алып барыла.

2. Беркетмә эчтәлегенә карата куелган таләпләрне Конституция суды Регламенты билгели. Судьяларның Конституция суды киңәшмәсендә әйтелгән фикерләре, киңәшмәнең барышы, Регламентта күрсәтелгән мәсьәләләрдән тыш, беркетмәгә теркәлми һәм игълан ителми.

3. Беркетмәнең тулылыгын тәэмин итү өчен стенография кулланырга мөмкин. Стенография юлы белән язганнар беркетмәгә теркәлми.

4. Конституция утырышы барышында сөйләгәннәрне яздырырга, видеоязмага яисә кинога төшерергә мөмкин. Бу очракта фонограмма, видеотасма яисә кинотасма утырыш беркетмәсенә утырышның бер өлеше буларак теркәлә, бу турыда беркетмәгә язып куела.

5. Беркетмә утырыш беткәннән соң яисә эш вакыты бетү сәбәпле, тәнәфес игълан ителгәннән соң өч тәүлектән дә соңга калмыйча әзерләнергә тиеш. Беркетмәгә, аның дөреслеген раслап, Конституция суды Рәисе һәм сәркатибе имза салалар.

39 маддә. Конституция суды утырышын әзерләү

I. Конституция суды утырышы Конституция суды Рәисе житәкчелегендә әзерләнә.

2. Конституция суды каравына тәкъдим ителүче мәсьәләләр алдан өйрәнелергә тиеш. Аңлашманамәләрнең, норматив актларның, урындагы затларның гамәлләренең һәм карарларының Конституциягә туры килү-килмәвен тикшерү турындагы әлеге Закон таләпләренә җавап бирүче үтенечләре һәм гарызнамәләре , шулай ук Конституция судының теләсә кайсы судьясының мәсьәләне карау турындагы язмача тәкъдимнәре Конституция суды тарафыннан алдан өйрәнелергә тиеш.

3. Конституция суды Рәисе мәсьәләне өйрәнүне бер яисә берничә судьяга йөкли һәм әлеге эшне тәмамлау вакытын билгели, ул ике айдан да артмаска тиеш. Мәсьәләне өйрәнә торган судья белешмә төзи һәм белешмәне Конституция суды Рәисенә, ә кирәге чыкканда, Конституция суды утырышында да хәбәр итә.

4. Конституция суды Рәисе һәм судьялары тәкъдимнәре буенча Конституция суды үз утырышларында каралырга тиешле мәсьәләләрне билгели, мәсьәләләрне карауга кабул итүе турында карарлар чыгара, чираттагы утырышларның көн тәртибен раслый, аларны уздыру вакытын һәм урынын билгели.

5. Мәсьәләне караргa әзерләү, Конституция судының карары, бәяләмәсе һәм башка нәтиҗәсе проектларын төзү, шулай утырышта материалларны уку өчен Конституция суды Рәисе нотык тотучы судьяны билгели. Нотыкчы судья бу мәсьәләне алдан өйрәнгән булырга тиеш.

6. Мәсьәләне өйрәнгәндә һәм аны карарга әзерләгәндә Конституция суды судьясы Конституция суды вәкаләтләре нигезендә кирәкле документларны һәм башка төрле материалларны таләп итәргә, тикшерү, өйрәнү, экспертиза эшләрен кушарга, белгечләр киңәшеннән файдаланырга, гарызнамәләр җибәрергә хаклы. Нотыкчы судья

һәм Конституция суды Рәисе утырышка чакырылучы һәм килүе мәжбүри булган затларны билгели, утырышның урыны һәм уздырылу вакыты турында белдерү кәгазе һәм тиешле затларны утырышка чакыру, шулай ук утырышта катнашучыларга кирәкле материаллар җибәрү турында боерыклар бирәләр.

7. Конституция суды утырышы турында белдерү кәгазе, утырышның көн тәртибе, карарларының, бәяләмәләренең һәм башка нәтиҗәләренең проектлары, ә кирәк булса, башка документлар Конституция суды судьяларына утырыш башланырга ун көннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

8. Конституция суды аерым документ рәвешендә бәян ителүе мәҗбүри булмаган яисә каралырга әзерләгән мәсьәләгә юлдаш булган мәсьәләне өйрәнүнең, Конституция суды утырышына кертүнең әлеге маддәдә билгеләнгән тәртибен үтәми генә, аны көн тәртибенә кертә һәм карарга әзерли ала.

40 маддә. Конституция суды тарафыннан мәсьәләләрне карау тәртибе

I. Рәислек итүче билгеләнгән вакытта Конституция суды утырышын ача һәм нинди мәсьәләләр каралачагын хәбәр итә. Рәислек итүче судьяларның җитәрлек санда булуын һәм беркетмә алып баруның тәэмин ителешен тикшерә, шулай ук якларның, шаһитларның һәм экспертларның килгәнен, яклар вәкилләренең вәкаләтләрен тикшерә.

2. Рәислек итүче якларга - аларның хокукларын һәм бурычларын, ә чакырылган затларга аларның бурычларын һәм җаваплылыкларын аңлатырга тиеш.

3. Һәр мәсьәләне карау нотыкчы судья чыгышыннан башлана, ул мәсьәләнең асылын, аны карауның сәбәбен һәм нигезен, булган материалларның эчтәлеген аңлата һәм мәсьәләне карауга әзерләү

чаралары турында хәбәр итә. Нотыкчы судьяга Конституция суды судьялары сораулар бирә алалар.

4. Шуннан соң яклар аңлатма бирәләр. Якларга Конституция суды судьялары һәм утырыштагы башка катнашучылар сораулар бирә алалар.

5. Кирәк чакта Конституция суды шаһитларның һәм экспертларның күрсәтмәләрен тыңлый, аларга сораулар бирә. Шаһитның һәм экспертның күрсәтмәләрен тыңлар алдыннан рәислек итүче алардан ант иттерә.

6. Конституция суды утырышында документлар укылырга мөмкин.

7. Конституция суды утырышында чакырылган затлар чыгыш ясарга мөмкин.

8. Аңлатмаларны, күрсәтмәләрне һәм документларны тикшереп бетергәч, Конституция суды утырышта рәсми катнашучыларның чыгышларын һәм якларның йомгаклау чыгышларын тыңлый.

9. Йомгаклау чыгышларыннан соң Конституция суды карар кабул итү өчен киңәшергә чыга. Кирәк булса,рәислек итүче үз теләге белән яисә теләсә кайсы судьяның таләбе буенча эшне яңадан карау яки аны хәл итүне кичектерү турындагы мәсьәләне тавышка куя, тавышка кую гамәлләре әлеге кагыйдәләргә нигезләнеп башкарыла.

10. Конституция суды тарафыннан мәсьәләләрне карау тәртибе тулырак итеп Конституция суды Регламентында бирелә.

41 маддә. Конституция суды карарлары

1. Конституция суды утырышында кабул ителә торган, аның ихтыярын белдерә яисә әлеге Закон нигезендә аерым шартларны раслый торган акт Конституция суды карары була.

 117

2. Халыкара аңлашманамәләрнең һәм норматив актларның Конституциягә туры килү-килмәүләре турында каралган эшләр буенча Конституция судының йомгаклау чыгарылмасы карар дип атала. Карарлар Татарстан Республикасы исеме белән Конституция суды тарафыннан чыгарыла.

3. Әлеге Законда каралган очракларда Конституция судының йомгаклау чыгарылмасы нәтиҗә дип атала.

4. Конституция судының юлламалары һәм тәкъдимнәре аның карарлары белән раслана.

5. Конституция судының таләпләре аның карарларында чагылырга яисә башка рәвештә бирелергә мөмкин.

42 маддә. Конституция суды тарафыннан карарлар кабул итү

I.Конституция суды карарлары - ачык тавыш бирү юлы белән, ә өчтән дә ким булмаган судьялар таләбе буенча яшерен тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Ачык тавыш бирү - кул күтәреп, ә судьяларның квалификацияле күпчелеге булуны таләп итүче мәсьәләләр буенча исемләп фикерләрен белү юлы белән башкарыла.

2. Рәислек итүче үтенечтә яисә карар проектында булган тәкъдимнәрне, шулай ук утырыш барышында судьялар тарафыннан әйтелгән тәкъдимнәрне керү тәртибендә тавышка куя. Эшне карау яисә нәтиҗәләр чыгару белән бәйләнмәгән Конституция суды утырышында рәислек итүче шушы утырышта катнашучы тарафыннан әйтелгән тәкъдимне тавышка куя.

3. Судьяның тавыштан тыелып калырга яисә тавыш бирүдә катнашмаска хакы юк. Исемләп фикерләрен белүдә тавыш бирүнең тәртибен рәислек итүче билгели. Рәислек итүче барлык очракларда да иң соңгы булып тавыш бирә.

4. Утырышта кворум булып, утырышта катнашучы судьяларның күпчелеге тавыш бирсә, Конституция суды карары кабул ителгән дип санала. Әгәр бер тәкъдим дә күпчелек тавышны җыймаса, рәислек итүче күбрәк тавыш җыйган ике тәкъдимне яңадан тавышка куя. Тавышлар тигез бүленгән очракларда, ә аңлашманамәнең, норматив актның урындагы затлар гамәлләренең яисә карарларының Конституциягә туры килүләре файдасына, башка мәсьәләләр буенча да рәислек итүче уңай тавыш бирсә, мәсьәлә хәл ителгән, нәтиҗә чыгарылган, карар кабул ителгән дип санала.

5. Конституция суды судьясының вәкаләтләрен туктатып тору яисә туктату, кагылгысызлыгын чикләү турындагы мәсьәләне караган очракларда карар Конституция суды әгъзаларының өчтән ике тавышы белән кабул ителә.

6. Әлеге Законда каралган очракларда Конституция суды үтенечне яисә гарызнамәне караудан баш тарту турында карар кабул итә, эшне туктата.

7. Конституция суды шулай ук эшне яңадан карау яисә кичектерү турында карар кабул итә ала.

43 маддә. Конституция суды судьясының аерым фикере

Конституция суды карары яисә нәтиҗәсе белән килешмәгән Конституция суды судьясы үзенең фикерен нигезләп, язма рәвештә бәян итәргә һәм әлеге язманы Конституция суды утырышының беркетмәсенә беркетеп куярга хаклы. Судья таләп итсә, әлеге фикер Конституция суды карары белән бергә бастырып чыгарылырга мөмкин.

44 маддә. Конституция суды карарларын бәян итү

I. Конституция суды карары, судьялар теләгенә карап, аерым документ рәвешендә яисә беркетмә буларак бәян ителә.

2.Аерым документлар рәвешендә Конституция суды карарлары һәм нәтиҗәләре, шулай ук Конституция суды судьяларының вәкаләтләрен туктату яки аның кагылгысызлыгын чикләү турында карарлар бәян ителә.

3. Аерым документ рәвешендә бәян ителгән Конституция суды карары дәлилләнгән булырга тиеш. Карарда чагылдырылган мәсьәләләрнең исемлеге Конституция суды Регламентында билгеләнә.

4. Конституция суды карарны кабул итүгә язма рәвештә бәян итә. Конституция суды, утырыш беркетмәсенә беркетелә торган карар тәгъбирен бәян итү белән генә чикләнеп, дәлилләнгән карарны төзүне ике атнадан да артыкка кичектерергә тиеш түгел.

5. Карарда төзәтмәләр рәислек итүче тарафыннан билгеләнә һәм аның имзасы белән раслана.

6. Аерым документ рәвешендә бәян ителгән Конституция суды карарына һәм аның бәян ителгән тәгъбиренә рәислек итүче һәм Конституция суды сәркатибе имза сала.

7. Конституция суды карар игълан ителгәннән соң атамаларда һәм билгеләмәләрдә киткән төгәлсезлекләрне, хәреф хаталарын, исәпләүдәге һәм редакцияләүдәге башка мәгълүм хаталарны төзәтә ала. Төгәлсезлекләрне, хәреф хаталарын һәм башка мәгълүм хаталарны төзәтү турында Конституция суды утырышында карар кабул ителә.

<u>45 маддә</u>. Конституция суды карарын игълан итү һәм аның гамәлгә керүе

Конституция суды карары яисә аның тәгъбире аерым документ рәвешендә бәян ителгәннән соң кичекмәстән игълан ителә. Беркетмә рәвешендә бәян ителгән Конституция суды карары аны кабул иткәннән соң кичекмәстән гамәлгә керә.

Конституция суды карары игълан ителгәнннән соң кичекмәстән гамәлгә керә.

46 маддә. Конституция суды карарын җибәрү

I. Аерым документ рәвешендә бәян ителгән Конституция суды карары кабул ителгәннән соң бер айдан да соңга калмыйча түбәндәгеләргә җибәрелә:

Конституция суды судьяларына;

Татарстан Республикасы Югары Советына, Татарстан Республикасв Президентына, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына;

Татарстан Республикасы Югары суды Рәисенә, Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды Рәисенә, Татарстан Республикасы Прокурорына, Татарстан Республикасының юстиция министрына;

якларга.

2. Конституция суды Рәисе Конституция суды карарын дәүләтнең һәм җәмәгатьчелекнең башка органнарына, шулай ук предприятиеләргә, учреждениеләргә, оешмаларга, урындагы затларга һәм гражданнарга җибәрү турында боерык бирә ала.

47 маддә. Конституция суды карарын аңлатып бирү

I. Конституция суды карарын утырышта катнашучылар, әлеге карар җибәрелгән башка органнар һәм затлар үтенече буенча яисә Конституция судының үз инициативасы белән бары тик Конституция суды үзе генә рәсми рәвештә аңлатып бирә ала.

2. Конституция суды карарын аңлатып бирү турында Конституция суды утырышында аерым документ рәвешендә бәян ителә торган карар кабул ителә.

3. Конституция суды үз карарын гамәли эчтәлеге нигезендә аңлатып бирергә тиеш һәм аңа карар кабул итү мизгелендә булмаган мәгънә өсти алмый.

48 маддә. Конституция суды карарын яңадан карау

I. Конституция суды карары үз инициативасы белән түбәндәге очракларда каралырга мөмкин, әгәр:

I/ Конституция суды карарны әлеге Законда билгеләнгән эш алып бару тәртибен җитди бозып кабул ителгән дип тапса;

2/ карар чыгарган вакытта Конституция судына мәгълүм булмаган яңа вакыйгалар ачылса;

3/ карар кабул ителгәндә нигез булып торган Конституция нормасы үзгәрсә.

2. Конституция судының үз карарына аңлатма бирү турындагы карары гамәли эчтәлеген туры китереп аңлатылмаган очракта шулай ук яңадан каралырга мөмкин.

49 маддә. Конституция суды юлламасы

I. Конституция суды, аның тарафыннан каралган материалларга нигезләнеп, Татарстан Республикасында конституциячел законлылыкның халәте турындагы юллама белән Татарстан Республикасы Югары Советына мөрәҗәгать итәргә хаклы. Конституция суды юлламасы аерым документ рәвешендә бәян ителә.

2. Конституция суды юлламасы Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан чираттагы сессиядән дә соңга калмыйча каралырга тиеш. Юлламаны карау нәтиҗәләре буенча карар кабул ителә.

50 маддә. Конституция суды тәкъдиме

I. Конституция суды, Татарстан Республикасы Конституциясен аерым бозуларны ачыклап, үзенең тәкъдиме аша вәкаләтле органнарның, урындагы затларның игътибарын мәгълүм бозуларга юнәлдерергә мөмкин. Конституция суды тәкъдиме аерым документ рәвешендә бәян ителә.

2. Конституция суды тәкъдиме дәүләт яисә җәмагать органы, шулай ук әлеге тәкъдим җибәрелгән предприятие, учреждение, оешма яки урындагы зат тарафыннан тәкъдим алынганнан соң бер айдан да

соңга калмыйча каралырга тиеш. Тәкъдимне карау нәтиҗәсендә кабул ителгән карарлар һәм аны гамәлгә ашыру буенча чаралар турында кичекмәстән Конституция судына хәбәр ителә.

Конституция судының тәкъдимнәрен карау кагыйдәләрен бозган өчен урындагы тиешле затларга әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә акчалата штраф салына.

51 маддә. Акчалата штраф салу турында Конституция суды карарлары

1. Конституция суды, үзенең намусын, абруен саклап, Конституция нигезендә суд эшләре алып баруның тиешле тәртибен һәм анда билгеләнгән кагыйдәләрнең үтәлешен тәэмин итеп, Конституция судына ихтирамсызлык күрсәтүдә гаепле урындагы затларга һәм гражданнарга акчалата штрафлар салырга хаклы.

2. Конституция суды закон бозган һәр очрак өчен гражданнарга һәм якларның вәкилләренә бер минималь хезмәт хакы күләмендә, ә урындагы затларга минималь хезмәт хакының бишләтелгән күләмендә штраф сала ала.

3. Акчалата штраф салу турындагы карар Конституция суды тарафыннан, кагыйдә буларак, беркетмә рәвешендә бәян ителә.

4. Закон бозучы штраф салу турында хәбәр алганнан соң ун көннән дә соңга калмыйча аны түләргә тиеш. Штраф түләүдән баш тарту яисә билгеләнгән вакытта штраф түләмәү очракларында Конституция суды карары,административ хокук бозулар турында эшләрне карау тәртибендә, Конституция суды утырышы беркетмәсеннән өземтә яисә аның карарының күчермәсе нигезендә мәҗбүри башкарыла.

2 кисәк. Халыкара аңлашманамәләрнең һәм норматив актларның Конституциягә туры килү-килмәве турындагы эшләрне карау

52 маддә. Халыкара аңлашманамәләрнең һәм норматив актларның Конституциягә туры килү-килмәвен тикшерү тәртибендә Конституция суды тарафыннан каралучы эшләр

I. Конституция суды түбәндәгеләрнең Конституциягә туры килү-килмәве хакындагы эшләрне карый:

I/ Татарстан Республикасы законнарының һәм Татарстан Республикасы Югары Советы һәм аның Президиумы карарларының;

2/ Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты норматив актларының;

3/ Татарстан Республикасы халыкара актларының.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды әлеге маддәнең беренче өлешендә күрсәтелгән актларның тулысынча һәм шулай ук аларның аерым өлешләренең Конституциягә туры килү-килмәве хакындагы эшләрне карый.

3. Конституция суды Татарстан Республикасының Югары дәүләт органнары арасындагы вәкаләтләр турында бәхәсләрне, шулай ук республика буйсынуындагы районнар һәм шәһәрләр хакимияте органнары арасындагы вәкаләтләр турында бәхәсләрне, шул исәптән алар тарафыннан хакимият бүленеше принципларын бозып кабул ителгән актларның Конституциягә туры килмәвен карый. Конституция суды әлеге каршылыкларны бәхәскә керүче теләсә кайсы якның инициативасы белән,шушы Законда һәм халыкара аңлашманамәләрнең һәм норматив актларның Конституциягә туры килү-килмәве хакындагы эшләр буенча Конституция суды Регламентында билгеләнгән тәртиптә карый.

53 маддә. Халыкара аңлашманамәләрнең һәм норматив актларның Конституциягә туры килү-килмәве хакындагы эшләрне карауның нигезләре һәм сәбәпләре

I. Халыкара аңлашманамәләрнең яисә норматив актларның Кон-

ституциягә туры килү-килмәве хакындагы эшләрнең Конституция судында каралуына аларның тулысынча яки өлешчә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве хакындагы мәсьәләдә мәгълүм булган билгесезлек нигез булып тора:

1/ максатлары һәм нормаларның эчтәлеге буенча;

2/ халыкара аңлашманамәдә яисә норматив актта кузгатылган мәсьәләләрнең характеры буенча;

3/ рәвеше буенча;

4/ имза салу, төзү, кабул итү, бастырып чыгару яисә гамәлгә кертү тәртибе буенча;

5/ Татарстан Республикасында закон чыгару, башкарма һәм хөкем хакимиятләренең билгеләнгән бүленешеннән чыгып;

6/ Татарстан Республикасының югары дәүләт органнары арасындагы вәкаләтләрнең Татарстан Республикасы Конституциясе тарафыннан беркетелгән чикләнешенә карап;

7/ Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе - Россия арасында вәкаләтләрнең һәм эш алып бару предметларының Татарстан Республикасы Конституциясе тарафыннан беркетелгән чикләнешенә карап.

2. Халыкара аңлашманамәнең яисә норматив актның Конституция-
гә туры килү-килмәве хакындагы эшләрне Конституция судында карауга әлеге Закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә кертелгән һәм аның таләпләренә җавап бирә торган үтенеч сәбәп була.

**54 маддә.** Халыкара аңлашманамәнең һәм норматив актның Конституциягә туры килү-килмәвен тикшерү турында үтенеч белән Конституция судына мөрәҗәгать итү

Халыкара аңлашманамәнең һәм норматив актның тулысынча яисә өлешчә Конституциягә туры килү-килмәвен тикшерү хакында үтенеч белән Конституция судына Татарстан Республикасы Югары

Советы, аның Президиумы, Татарстан Республикасы Югары Советының даими комиссияләре һәм Парламент тикшерүе комитеты, Татарстан Республикасы халык депутатларының 20 кешедән дә ким булмаган төркеме, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, Татарстан Республикасының Югары суды, Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды, Татарстан Республикасы Прокуроры, халык депутатларының район, шәһәр /республика буйсынуындагы шәһәрләр/ Советы, сәяси фиркаләр, профессиональ берлекләр һәм башка җәмәгать оешмалары үзләренең республика органнары сыйфатында мөрәҗәгать итә алалар.

2. Әгәр әлеге матдәнең беренче өлешендә күрсәтелгән дәүләт яисә җәмәгать органнары, урындагы затлар һәм Татарстан Республикасы халык депутатлары төркеме халыкара аңлашманамәне яисә норматив актны Конституциягә туры килмәү сәбәпле гамәлгә яраксыз дип санасалар яисә, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми торган халыкара аңлашманамәне яки норматив актны кулланмаучы яисә кулланудан баш тартучы Татарстан Республикасы Югары дәүләт органнарының яки урындагы затларның фикерләренә каршы килеп, гамәлгә яраклы дип санасалар, үтенеч кабул ителә.

3. Халыкара аңлашманамәнең, норматив актның Конституциягә туры килү-килмәвен тикшерү турында үтенеч белән Конституция судына мөрәҗәгать итәргә хокукы булмаган дәүләт һәм җәмәгать органнары, шулай ук предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, урындагы затлар һәм гражданнар әлеге хокукка ия булган дәүләт һәм җәмәгать органнары, урындагы затлар һәм халык депутатлары алдында тиешле инициатива белән чыгалар. Инициатива карала һәм аны карау нәтиҗәләре турында Конституция судына мөрәҗәгать итүчегә билгеләнгән тәртиптә хәбәр ителә.

55 маддә. Халыкара аңлашманамәнең һәм норматив актның Конституциягә туры килү-килмәвен Конституция суды тарафыннан тикшерү турында үтенеч

I. Үтенечтә түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш:

I/ үтенеч белән мөрәҗәгать итәрлек орган сыйфатында Конституция суды;

2/ үтенеч бирүченең исеме /атамасы/, урыны, адресы һәм аның турында башка мәгълүматлар;

3/ үтенеч бирүченең вәкиле һәм аның вәкаләтләре турында кирәкле мәгълүматлар, моңа вәкиллек итүне вазыйфалар нигезендә башкару очрагы керми;

4/ Конституциягә туры килү-килмәве тикшерелә торган халыкара аңлашманамәгә имза салган яисә норматив акт бастырып чыгарган дәүләт органының исеме, урыны һәм адресы; тиешле очракта - Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми торган халыкара аңлашманамәне яисә норматив актны кулланмаучы яки аны куллanудан баш тартучы Татарстан Республикасы югары дәүләт органының яисә урындагы затларның исеме, урыны һәм адресы, ә кирәк чакта - башка якларныкы да;

5/ Татарстан Республикасы Конституциясенең һәм әлеге Законның Конституция судына үтенеч белән мөрәҗәгать итәрлек хокук бирүче нормалары;

6/ күз алдында тотылучы аңлашманамәнең яисә норматив актның төгәл исеме, номеры, кабул итү көне, басылу чыганагы һәм башка кирәкле мәгълүматлары;

7/ эшне әлеге Законда тәгъбир ителгәнчә һәм аның тиешле нормаларына таянып карау өчен төгәл нигезләр;

8/ тиешле очракта, халыкара аңлашманамәне яки норматив актны куллaнудан баш тарту турында мәгълүматлар китереп, үтенеч кертү кирәклеген нигезләү;

9/ халыкара аңлашманамәнең, норматив актның Конституциягә туры килү-килмәве хакында үтенеч бирүченең карашлары һәм законнарның тиешле нормаларына таянып бәян ителгән әлеге карашларны дәлилләү;

10/ Конституция судына үтенеч бирүгә бәйле мөрәҗәгать;

11/ үтенечкә теркәлүче документлар исемлеге.

2. Үтенеч кәгазенә үтенеч белән мөрәҗәгать итүче дәүләт һәм җәмәгать органы җитәкчесе,урындагы зат яисә Татарстан Республикасы халык депутатлары төркеменә керүчеләрнең барысы да имза сала.

3. Үтенечкә түбәндәгеләр теркәлә:

1/ Конституциягә туры килү-килмәве тулысынча яисә өлешчә тикшерелүче халыкара аңлашманамәнең яки норматив актның тулы тексты күчермәсе;

2/ тиешле очракта - Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип, халыкара аңлашманамәне яисә норматив актны кулланмаучы яки аңардан баш тартучы Татарстан Республикасы дәүләт органнарының яки урындагы затларының карарлары күчермәсе;

3/ вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы ышанычнамә /доверенность/ яки башка документ, моңа вазыйфалары буенча вәкил булу керми, шулай ук Конституция суды алдында вәкил буларак чыгыш ясарга хокук бирүче документларның күчермәләре;

4/ дәүләт пошлинасын түләү турында документ;

5/ башка телләрдә бәян ителгән барлык документларның һәм башка материалларның татар һәм урыс телләренә тәрҗемәсе;

4. Үтенеч кәгазенә шулай ук Конституция суды утырышына чакырылырга тәкъдим ителүче шаһитлар һәм экспертлар исемлеген, үтенечтә кузгатылган мәсьәләләр буенча белгечләр бәяләмәләрен, шулай ук башка документларны һәм материалларны беркетергә мөмкин.

5. Үтенеч кәгазе һәм аңа тиешле өстәмәләр Конституция судына күчермәләре белән бергә өчтән дә ким булмаган нөсхәдә тәкъдим ителә. Конституция суды рәисе, каралучы эшнең катлаулылыгыннан һәм характерыннан чыгып, үтенеч бирүчедән үтенеч кәгазенә теркәлгән башка документларның һәм материалларның күчермәләрен тиешле санда таләп итәргә хаклы.

56 маддә. Халыкара аңлашманамәнең һәм норматив актның Конституция суды тарафыннан Конституциягә туры килү-килмәвен тикшерү турындагы үтенечкә бәяләмә

Үтенеч Конституция суды Рәисе рөхсәте белән үтенеч белән мөрәҗәгать итүче дәүләт яки җәмәгать органы, урындагы зат һәм Татарстан Республикасы халык депутатлары төркеме тарафыннан тиешле мәсьәләне Конституция суды утырышының көн тәртибенә кертәнче кире алынырга мөмкин.

57 маддә. Халыкара аңлашманамәнең һәм норматив актның Конституция суды тарафыннан Конституциягә туры килү-килмәвен тикшерү турындагы үтенечне караудан баш тарту

I. Конституция суды халыкара аңлашманамәнең һәм норматив актның Конституциягә туры килү-килмәвен тикшерү турындагы үтенечне караудан түбәндәге очракларда баш тарта, әгәр:

I/ үтенеч эчтәлеге буенча әлеге Закон таләпләренә туры килмәсә яки кабул итәрлек булмаса;

2/ үтенеч тиешле органнан,заттан яисә төркемнән кермәсә;

3/ үтенеч Конституция судында эш алып баруга вәкаләтләре булмаган вәкилдән бирелгән булса;

4/ әлеге үтенечне карау Конституция суды карамагына кермәсә;

5/ халыкара аңлашманамәнең, норматив актның яисә аның бер өлешенең Конституциягә туры килү-килмәвен тикшерү турындагы үтенеч Конституция суды тарафыннан тикшерелгән һәм тикшерү нәтиҗәсендә, әлеге Закон билгеләгән тәртиптә, үзенең гамәли көчен

саклаучы карар кабул ителгән булса;

6/ Конституциягә туры килү-килмәвен тикшерергә тәкъдим ителгән халыкара аңлашманамә яисә норматив акт тарафыннан хәл ителә торган мәсьәлә Татарстан Республикасы Конституциясендә хәл ителмәсә, аны дөрес хәл итүнең ысулы Татарстан Республикасы Конституциясенең гомуми башлангычларыннан һәм мәгънәсеннән чыгарыла алмый яисә бу мәсьәлә үзенең характеры һәм әһәмияте буенча Конституциягә туры килү-килмәвен тикшерүгә карамаса;

7/ үтенече Конституция суды Рәисе тарафыннан кайтарып бирелгән яки, үтенечне яңадан биргәндә, җитешсезсезлекләрнең барысын да төзәтмәгән булса яисә аларны билгеләнгән вакыттан узып төзәткән булса.

2. Үтенечне караудан баш тартуга сәбәпләр турында эшне Конституция суды утырышында карый башлагач ,билгеләнгән очракларда эшне туктату турында карар кабул ителә.

3. Конституциягә туры килү-килмәве тикшерелергә тиешле аңлашманамә, норматив акт кире кагылса яки эшне карауга керешер алдыннан яисә карау барышында көчен югалтса, Конституция суды эшне караудан баш тартырга һәм башланган эшне туктатырга мөмкин.

4. Билгеләнгән кагыйдәләр эшне карау барышында Конституция нигезендә тәртипкә китерелеп, эшне карауга нигезләр бетсә, Конституция суды аңлашманамәнең яисә норматив актның Конституциягә туры килү-килмәве турында башлаган эшне туктата.

58 маддә. Халыкара аңлашманамәнең, норматив актның Конституция суды тарафыннан Конституциягә туры килү-килмәвен тикшерү хакындагы үтенечне кире кайтару

I. Конституция суды Рәисе Конституция суды утырышын әзерләү тәртибендә, шулай ук Конституция суды үтенечне тутыруда җибәрелгән җитешсезлекләрне төзәтүнең зарурлыгын күрсәтеп,түбәндәге очракларда үтенечне тиешле якка кире кайтаралар, әгәр:

1/ үтенеч яисә аңа өстәмәләр рәвешләре буенча әлеге Закон таләпләренә туры килмәсә;

2/ үтенечкә кирәкле документлар һәм башка материаллар өстәлмәгән булса;

3/ үтенеч яисә аңа өстәмәләрнең күчерелмәләре Конституция судына тиешле санда бирелмәсә;

4/ як тарафыннан дәүләт пошлинасы түләнмәгән яисә тулысынча түләнмәгән булса яисә дәүләт пошлинасын түләү турында документ беркетелмәгән булса.

2. Үтенечне язуда күрсәтелгән кимчелекләр як тарафыннан Конституция суды күрсәтмәләре бирелгән мизгелдән башлап бер айдан да соңга калмыйча бетерелергә тиеш.

**59 маддә.** Халыкара аңлашманамәнең һәм норматив актның Конституция суды тарафыннан Конституциягә туры килү-килмәвен тикшерү турындагы эш буенча кабул ителә торган йомгаклау карарларының төрләре

1. Халыкара аңлашманамәнең һәм норматив актның Конституциягә туры килү-килмәвен тикшерү хакындагы эшне карау нәтиҗәләре буенча Конституция суды түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1/ халыкара аңлашманамәнең яисә норматив актның Татарстан Республикасы Конституциясенә тулысынча яисә өлешчә туры килүе турында;

2/ халыкара аңлашманамәнең яисә норматив актның Татарстан Республикасы Конституциясенә тулысынча яисә өлешчә туры килмәве турында.

2. Әлеге маддәнең 2 пунктындагы беренче өлешендә каралган очракта шушы Законда каралган нинди сәбәпләр буенча халыкара аңлашманамәнең яисә норматив актның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килмәве күрсәтелә.

3. Халыкара аңлашманамәнең яисә норматив актның бер өлеше Конституциягә туры килгән һәм бер өлеше Конституциягә туры килмәгән очракта яисә бер үк эш буенча халыкара аңлашманамәләрнең яисә норматив актларның бер ишесе Конституциягә туры килә, икенчеләре Конституциягә туры килми дип саналсалар, бу хакта Конституция суды карарында күрсәтелә.

60 маддә. Халыкара аңлашманамәнең һәм норматив актның Конституциягә туры килмәвен тануның нәтиҗәләре

1. Халыкара аңлашманамәнең яисә аның аерым өлешенең Конституциягә туры килмәвен тану турында Конституция суды карары үз көченә кергән мизгелдән аңлашманамә яисә аның аерым өлеше ратификацияләнә алмый, рәсми рәвештә басыла, халыкка игълан ителә һәм гамәлгә кертелә алмый; ә элек ратификацияләнгән яисә гамәлгә кертелгән булса, Конституция судының карары үз көченә кергән мизгелән ул гамәлдән чыккан дип исәпләнә. Конституция суды тарафыннан халыкара аңлашманамәнең яисә аның өлешенең Конституциягә туры килмәвен тану турында Конституция суды карары үз көченә кергәннән соң кабул ителгән халыкара аңлашманамәне ратификацияләү һәм аны гамәлгә кертү турында карарлар шулай ук тулысынча яисә өлешчә көчләрен югалталар.

2. Норматив актның яисә аның аерым өлешенең Конституциягә туры килмәвен тану турында карар үз көченә кергән мизгелдән норматив акт яисә аның тиешле өлеше рәсми рәвештә басыла алмый, халыкка игълан ителә яисә гамәлгә кертелә алмый, ә элек гамәлгә кертелгән булса, гамәлдән чыккан дип исәпләнә. Норматив актны гамәлгә кертү турындагы карарлар шулай ук тулысынча яки өлешчә көчләрен югалталар. Конституция суды бер үк вакытта Конституциягә туры килмәве танылган норматив актка һәм аны тәшкил итүче положениеләргә нигезләнгән башка норматив актларның положениеләре эчтәлеге.. дә гамәлдән чыккан дип таный ала,

бу хакта карарда күрсәтелә. Мондый күрсәтмә булмаса, Конституциягә туры килмәве танылган норматив актка һәм аны тәшкил итүче положениеләргә нигезләнгән башка норматив актларның положениеләре судлар һәм башка органнар , урындагы затлар тарафыннан кулланыла алмыйлар һәм билгеләнгән тәртиптә гамәлдән чыгарылырга тиешләр.

3. Судьяларның һәм башка хокук саклау органнарының Конституциягә туры килмәве танылган халыкара аңлашманамәләргә, шулай ук норматив актларга нигезләнгән карарлары,әгәр мондый карарлар Конституция судының тиешле карарлары үз көчен алу мизгеленә гамәлгә ашырылмаган булсалар, үтәлмиләр.

4. Конституция суды тарафыннан норматив актның Конституциягә туры килмәве танылу нәтиҗәсендә әлеге мәсьәлә буенча әлек гамәлдә булган норматив актлар гамәлдән чыгарылган яисә үз көчләрен югалткан очракта, соңгысына аның гамәли көче кайтарылырга мөмкин, әгәр бу турыда Конституция суды карар бирсә.

5. Конституция суды халыкара аңлашманамәнең яисә норматив актның Конституциягә туры килмәвен тану турында үзенең карарын үткән вакыт өчен гамәлгә кертә ала, әмма өч елдан да артмаска тиеш. Бу очракта Конституциягә туры килмәве танылган норматив актка нигезләнеп корылган хокукый мөнәсәбәтләр бу норматив актны кулланганчыга кадәр булган халәткә яисә Конституция суды карары кабул ителгәннән соң үз көчен саклаган норматив күрсәтмәләргә туры килә торган халәткә китерелә.

6. Халыкара аңлашманамәнең яисә аның аерым өлешенең Конституциягә туры килмәвен тану турында Конституция суды карарының көче яңа бәяләмә белән яисә әлеге халыкара аңлашманамәне яки аның өлешен ратификацияләү белән юкка чыгарылмый.

7. Норматив актның яисә аның аерым өлешенең Конституциягә туры килмәвен тану турында карарының көче әлеге норматив актны яки аның өлешен яңадан кабул итү белән юкка чыгарылмый.

3 бүлек

Нәтиҗәләр чыгару

61 маддә. Гарызнамәләр буенча һәм үз белдеге белән Конституция суды тарафыннан нәтиҗәләр чыгару

1. Конституция суды Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Югары Советы яисә аның Президиумы, даими комиссияләр һәм Парламент тикшерүе комитеты гарызнамәсе буенча, шулай ук үз белдеге белән түбәндәгеләр турында нәтиҗәләр чыгара:

1/ Татарстан Республикасы Президентының, шулай ук башка югары урыннардагы затларның Конституциягә туры килмәгән гамәлләре һәм карарлары Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә аларны биләгән урыннарыннан азат итүгә яки башка төрле махсус җаваплылыкка җәлеп итүгә нигез булса, аларның кылган гамәлләренең һәм карарларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килүе турында;

2/ Россия Федерациясенең - Россиянең Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарының һәм башка норматив актларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килүе турында.

2. Конституция судына аның утырышларында норматив актның Конституциягә туры килү-килмәве карала торган мәсьәләләр буенча нәтиҗәләр чыгарырга рөхсәт ителми.

62 маддә. Конституция суды тарафыннан нәтиҗә чыгару турында гарызнамә

1. Конституция суды судьясының язма тәкъдиме белән бергә Конституция суды тарафыннан нәтиҗә чыгаруга гарызнамә дә сәбәп була.

2. Гарызнамәдә түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш:

1/ гарызнамә бирелгән орган сыйфатында Конституция суды;

2/ гарызнамә бирүченең исеме, урыны һәм адресы;

3/ Татарстан Республикасы Конституциясенең һәм әлеге Законның Конституция судына гарызнамә белән мөрәҗәгать итү хокукы бирә торган нормалары;

4/ Конституциягә туры килү-килмәве тикшерелүче гамәлләр, аларны башкару шартлары, ә аңлашманамәләрне, норматив актларны яисә карарларны тикшергәндә – күз алдында тотылучы аңлашманамәнең, норматив актның яки карарның төгәл исеме, номеры, кабул ителгән көне һәм аны билгеләү өчен кирәкле башка мәгълүматлар, басылу чыганаклары /әгәр алар басылган булса/;

5/ Конституция судына гарызнамә белән мөрәҗәгать итүгә бәйле таләп;

6/ гарызнамәгә теркәлгән документлар исемлеге.

3. Гарызнамәгә Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе яки аны алмаштыручы зат, даими комиссия рәисе, Парламент тикшерүе комитеты рәисе тарафыннан имза салына.

4. Гарызнамәгә түбәндәгеләр теркәлә:

1/ тикшерелүче аңлашманамәнең, норматив актның яисә карарның тулы тексты күчермәсе;

2/ Татарстан Республикасының югары урындагы затларының тиешле гамәлләренең дәлилләре яисә тиешле карарларының күчермәләре;

3/ дәүләт пошлинасын түләү турында документ;

4/ башка телдә бәян ителгән материалларның Татарстан Республикасы дәүләт телләренә тәрҗемәсе;

5/ башка кирәкле документлар һәм материаллар.

5. Гарызнамә һәм аңа мәҗбүри өстәмәләр Конституция судына өчтән дә ким булмаган нөсхәдә күчермәләре белән бирелә.

63 маддә. Конституция суды тарафыннан нәтиҗә чыгару турындагы гарызнамәгә бәяләмә

I. Гарызнамә, Конституция суды утырышында карала башлаганчы, аны җибәргән орган тарафыннан, ә Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы, даими комиссия, Парламент тикшерүе комитеты гарызнамәсе - шулай ук Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан кире алынырга мөмкин.

64 маддә. Конституция суды тарафыннан нәтиҗә чыгару турындагы гарызнамәне караудан баш тарту

1. Конституция суды түбәндәге очракларда нәтиҗәләр чыгару турындагы гарызнамәне караудан баш тарта, әгәр:

I/ гарызнамә эчтәлеге белән әлеге Закон таләпләренә туры килмәсә;

2/ гарызнамә тиешле органнан кермәсә;

3/ әлеге гарызнамәне карау Конституция суды карамагында булмаса;

4/ Конституциягә туры килү-килмәве тикшерелергә тиешле гамәлләрнең һәм карарларның булмавы тиешле тәртиптә ачыкланса, гарызнамә урынсыз була;

5/ гарызнамәдә күрсәтелгән аңлашманамәләрнең яисә норматив актларның, гамәлләрнең яки карарларның Конституциягә туры килү-килмәве Конституция суды тарафыннан тикшерелгән һәм тикшерү нәтиҗәсендә әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә үз көчен саклаучы нәтиҗә чыгарылган булса;

6/ Конституция суды рәисе тарафыннан гарызнамәне кайтарып биргәндә күрсәтелгән кимчелекләр бетерелмәгән яисә аларны бетерү вакыты узган булса.

2. Эшне карый башлау мизгеленә аңлашманамә яисә норматив акт ниндидер сәбәпләр аркасында үз көчен югалтса, Конституция суды нәтиҗә чыгару турындагы гарызнамәне караудан баш тарта ала.

65 маддә. Конституция суды тарафыннан нәтиҗә чыгару турында гарызнамәне кире кайтару

I. Гарызнамәне язганда җибәрелгән җитешсезлекләрне төзәтүнең зарурлыгын күрсәтеп, Конституция суды утырышын әзерләү тәртибендә Конституция суды Рәисе, шулай ук Конституция суды түбәндәге очракларда гарызнамәне кире кайтара, әгәр:

I/ гарызнамә яисә аңа өстәмәләр рәвешләре буенча әлеге Закон таләпләренә туры килмәсәләр;

2/ гарызнамәгә кирәкле материаллар һәм башка материаллар беркетелмәгән булса;

3/ гарызнамәнең яисә аңа өстәмәләрнең күчермәләре Конституция судына тиешле санда бирелмәсә;

4/ дәүләт пошлинасы түләнмәгән яисә тулысынча түләнмәгән, яисә дәүләт пошлинасын түләү турында документ беркетелмәгән булса.

2. Гарызнамә язганда җибәрелгән кимчелекләр Конституция суды күрсәтмәләрен алган мизгелдән башлап бер айдан да соңга калмыйча бетерелергә тиеш.

66 маддә. Конституция суды нәтиҗәсенең әһәмияте

I. Татарстан Республикасының югары урындагы затлары гамәлләренең һәм карарларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турында Конституция судының нәтиҗәсе, бу гамәлләрне һәм карарларны билгеләгән очракта, аларның Конституциягә туры килү-килмәвен Конституция судының әлеге нәтиҗәсе нигезендә танырга мәҗбүр итә.

2. Россия Федерациясе - Россия законнарының һәм башка норматив актларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәүләре турындагы Конституция судының нәтиҗәсе, әлеге матдәнең беренче өлешендә каралмаган башка очраклардагы кебек, консультатив әһәмияткә ия.

IУ бүлек

Йомгаклау положениеләре

67 маддә. Конституция суды секретариаты

I. Конституция суды секретариаты мәгълүмат-белешмә эшен һәм башка ярдәмче эшләр башкара, гражданнарны кабул итүне оештыра, башлангыч тәртиптә Конституция судына мөрәҗәгатьләрне карый һәм, алар Конституция суды судьялары тарафыннан өйрәнүне таләп итми торган мәсьәләләргә кагылган очракларда, мәсьәләләрне өйрәнүдә һәм аларны карауга әзерләүдә булыша.

2. Конституция суды секретариаты турында положение, аның төзелеше һәм штат расписаниясе Конституция суды тарафыннан раслана.

68 маддә. "Татарстан Республикасының Конституция суды хәбәрләре"

Конституция суды "Татарстан Республикасының Конституция суды хәбәрләре"н чыгара.

69 маддә. Конституция суды материалларын бастырып чыгару

I. Конституция судының аерым документ рәвешендә бәян ителгән карарлары, бәяләмәләре һәм нәтиҗәләре, аның юлламалары Татарстан Республикасының рәсми матбугат органнарында, аларны бәян иткәннән соң җиде көннән дә соңга калмыйча, шулай ук "Татарстан Республикасы Югары Советы җыелма басмасы"нда һәм

"Татарстан Республикасының Конституция суды хәбәрләре"ндә басылып чыгарга тиешләр. Аңлашманамәләрнең һәм норматив актларның карарлары Конституция суды карары буенча Конституциягә туры килмәве танылган аңлашманамә яисә норматив акт басылган матбугат органында басылырга тиеш.

2. "Татарстан Республикасының Конституция суды хәбәрләре"ндә шулай ук Конституция суды утырышларының хисаплары, аның эшчәнлеге турында башка материаллар басыла.

70 маддә. Татарстан Республикасы Конституция судының эшчәнлеген финанслау

I. Конституция судының эшчәнлеге Татарстан Республикасының республика бюджеты исәбенә Конституция судының эшчәнлеген тиешенчә тәэмин итү өчен кирәкле күләмнәрдә финанслана.

2. Конституция судының штат саны, аның төзелеше һәм штат расписаниесе, шулай ук Конституция судының чыгымнар сметасы Конституция суды Рәисе тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан раслана.

3. Конституция судының мәҗбүри таләпләрен үтәү белән бәйле чыгымнарны дәүләт һәм җәмәгать органнары, шулай ук тиешле таләпләрне үтәү йөкләнгән предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар түли.

71 маддә. Конституция судын саклау

Конституция суды биләгән бинаны һәм бүлмәне саклау, ә кирәк чакта - Конституция суды судьяларын һәм аларның гаилә әгъзаларын, алар биләгән торак урыннарны һәм аларның мөлкәтләрен саклау эчке эшләр органнарына йөкләтелә.

72 маддә. Конституция судының хөкем хакимияте символлары

I. Конституция судының утырышлар залында Татарстан Республикасының Дәүләт гербы сурәте, Татарстан Республикасының Дәүләт

флагы, Татарстан Республикасы Конституциясе басмасы булырга тиеш.

2. Конституция суды судьялары утырышларда мантия киеп утыралар, аларның тасвирламасы һәм үрнәге Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы тарафыннан билгеләнә.

73 маддә. Конституция судының мөһере

Конституция судының Татарстан Республикасының Дәүләт гербы төшерелгән һәм үз исеме күрсәтелгән мөһере була.

74 маддә. Конституция судының урнашкан җире

Конституция судының даими урнашкан җире Татарстан Республикасының башкаласы Казан шәһәре була.

Конституция суды үз утырышын читтә уздыра ала.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1992 елның 22 декабре.
№ 1708-XII